ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 605 2017 елның 29 сентябре

# Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетның 2017 елның 12 маендагы 319 номерлы «Татарстан Республикасы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлегендә субсидияләр рәвешендә дәүләт ярдәме күрсәтү өчен кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын сайлап алу тәртибе турында» карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014-2020 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацияле икътисады» Дәүләт программасын раслау турында» 2013 елның 31 октябрендәге 823 номерлы карары белән расланган «2014-2020 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацияле икътисады» Дәүләт программасының «2014-2017 елларга Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү» ярдәмче программасы, Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 28 декабрендә кабул ителгән 1740 номерлы карары белән расланган «2017-2020 елларга «Түбән Кама шәһәре» муниципаль берәмлегенең кече һәм урта эшкуарлыгына ярдәм һәм аны үстерү» муниципаль программасы нигезендә, карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 12 маендагы 319 номерлы карары белән расланган субсидияләр рәвешендә ярдәм күрсәтү өчен Татарстан Республикасы «Түбән Кама шәһәре» муниципаль берәмлегенең кече һәм урта эшкуарлык субъектларын сайлап алу тәртибенә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 2.2 пунктының беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Субсидия бирүгә шартнамә төзү өчен кирәкле документларны тапшыру вакытына»;

1.2. 7 бүлекне түбәндәге эчтәлекле 7.8 пункты белән тулыландырырга:

«7.8. Мөрәҗәгать итүченең әлеге Тәртипнең 2.2 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килүе субсидия бирүгә шартнамә төзү өчен кирәкле документлар пакеты составында тапшырыла торган документлар, шулай ук түбәндәге документларда булган мәгълүмат нигезендә билгеләнә: Россия Федерациясе Федераль салым хезмәтенең 2017 елның 20 гыйнварындагы ММВ-7-8/20@ боерыгы белән расланган һәм Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланган форма буенча субсидия бирүгә шартнамә төзү планлаштырыла торган ай алдыннан килгән айның беренче числосыннан да алда бирелмәгән Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына

салымнар һәм җыемнар турындагы законнар нигезендә түләнергә тиешле салым, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча эшкуарлык субъектының үтәлмәгән йөкләмәләре булмавын раслаучы салым органы белешмәсе;

субсидия бирүгә шартнамә төзү өчен кирәкле һәм Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә расланган документлар тапшырганчы 30 календарь көннән дә иртәрәк бирелмәгән Юридик затларның (шәхси эшкуарларның) бердәм дәүләт реестрыннан өземтә.

Вәкаләтле орган әлеге документларны Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә ала.

Мөрәҗәгать итүче шулай ук Вәкаләтле органга әлеге пунктта күрсәтелгән документларның расланган күчермәләрен тапшырырга хокуклы.»;

1.3. 8 бүлекне түбәндәге эчтәлектәге 8.8 пункты белән тулыландырырга:

«8.8. Мөрәҗәгать итүченең 2.2 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килүе субсидия бирү өчен шартнамә төзү өчен кирәкле документлар пакеты составында тапшырыла торган документлар, шулай ук түбәндәге документларда булган мәгълүмат нигезендә билгеләнә:

мөрәҗәгать итүченең әлеге Тәртипнең 2.2 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килүе субсидия бирүгә шартнамә төзү өчен кирәкле документлар пакеты составында тапшырыла торган документлар, шулай ук түбәндәге документларда булган мәгълүмат нигезендә билгеләнә: Россия Федерациясе Федераль салым хезмәтенең 2017 елның 20 гыйнварындагы ММВ-7-8/20@ боерыгы белән расланган һәм Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланган форма буенча субсидия бирүгә шартнамә төзү планлаштырыла торган ай алдыннан килгән айның беренче числосыннан да алда бирелмәгән Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар һәм җыемнар турындагы законнар нигезендә түләнергә тиешле салым, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча эшкуарлык субъектының үтәлмәгән йөкләмәләре булмавын раслаучы салым органы белешмәсе;

субсидия бирүгә шартнамә төзү өчен кирәкле һәм Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә расланган документлар тапшырганчы 30 календарь көннән дә иртәрәк бирелмәгән Юридик затларның (шәхси эшкуарларның) бердәм дәүләт реестрыннан өземтә.

Вәкаләтле орган әлеге документларны Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә ала.

Мөрәҗәгать итүче шулай ук Вәкаләтле органга әлеге пунктта күрсәтелгән документларның расланган күчермәләрен тапшырырга хокуклы.»;

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.И. Беляевка йөкләргә.

А.Г. Сәйфетдинов